ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Конституция судын бетерү, Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 20 октябрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясе суд системасы турында» 1996 елның 31 декабрендәге 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон, «Аерым федераль конституциячел законнарга үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 декабрендәге 7-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон (алга таба – «Аерым федераль конституциячел законнарга үзгәрешләр кертү турында» Федераль конституциячел закон), «Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» 1992 елның 26 июнендәге 3132-I номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба – «Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законы), Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судын бетерүгә бәйле мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Татарстан Республикасы Конституция судын бетерү**

Татарстан Республикасы Конституция суды 2022 елның 31 декабрендә бетерелә.

3 статья. **Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының вәкаләтләрен туктату**

1. «Аерым федераль конституциячел законнарга үзгәрешләр кертү турында» Федераль конституциячел закон үз көченә кергән көнгә гамәлдә булган Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының вәкаләтләре 2022 елның 30 декабрендә туктатыла. Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының вәкаләтләрен туктату турындагы карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән рәсмиләштерелә.

2. Әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә вәкаләтләре туктатылган Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы отставкага киткән дип санала.

3. Әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә вәкаләтләрен үтәүне туктаткан Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларына, шулай ук вәкаләтләрен үтәүне элегрәк туктаткан Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларына таныклыклар тапшырыла. Таныклыкны тапшыру тәртибе һәм аның тасвирламасы турында нигезләмә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслана.

4 статья. **Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларына һәм Татарстан Республикасы Конституция суды аппаратының дәүләт граждан хезмәткәрләренә гарантияләр**

1. Әлеге Законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә вәкаләтләрен үтәүне туктаткан Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларына, шулай ук вәкаләтләрен үтәүне элегрәк туктаткан Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларына (алга таба – Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьясы) Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьялары өчен каралган Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән гарантияләр (матди һәм социаль тәэминатны да кертеп) саклана.

2. Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьясына үзенең теләге буенча йә гомуми нигезләрдә пенсия, йә салым салынмый торган ай саен гомерлек акчалата түләү билгеләнә.

3. Әлеге Законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә вәкаләтләрен үтәүне туктаткан Татарстан Республикасы Конституция суды судьясына ай саен гомерлек акчалата түләү ул киткән вазыйфа буенча «Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә исәпләнә торган айлык акчалата бүләкләүнең 80 проценты күләмендә билгеләнә. Судья булып эшләү стажы 15 елдан артыграк булган отставкадагы судьяга ай саен гомерлек акчалата түләү түбәндәгеләрдән чыгып арттырыла: 15 елдан артыграк эш стажының һәрбер елы өчен – күрсәтелгән бүләкләүнең бер проценты күләмендә, ләкин барлыгы ул киткән вазыйфа буенча айлык акчалата бүләкләүнең 85 процентыннан артык түгел. Гыйльми дәрәҗә яисә гыйльми исем, «Россия Федерациясенең Атказанган юристы» мактаулы исеме өчен өстәмә түләү алу хокукы булган судьялар өчен ай саен гомерлек акчалата түләү күләме, бу өстәмә түләүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының отставкага чыккан көненә билгеләнгән айлык акчалата бүләкләүнең 85 процентыннан артыграк була алмый. Монда Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вазыйфасында ай саен гомерлек акчалата түләүне санаганда исәпкә алына торган эш стажына Россия Федерациясе судьясы вазыйфасында эшләү вакыты, судлар аппаратларында биләү өчен югары юридик белем таләп ителә торган вазыйфаларда элек эшләү, шулай ук прокурор, тикшерүче, адвокат булып эшләү вакыты кертелә.

4. Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьясына ай саен гомерлек акчалата түләү федераль законнарда гомуми юрисдикциядәге федераль судлар судьялары өчен каралган нигезләр буенча туктатыла, бетерелә.

5. Татарстан Республикасы Конституция судының отставкага киткән судьясына «Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә эштән киткәндә бирелә торган пособие түләнә.

6. Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьяларына гарантияләр бирү тәртибе Татарстан Республикасы Президенты указы белән билгеләнә.

7. Татарстан Республикасы Конституция суды аппаратының Татарстан Республикасы Конституция суды бетерелүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә дәүләт граждан хезмәте турында законнарда билгеләнгән дәүләт гарантияләре тәэмин ителә.

5 статья. **Татарстан Республикасы Конституция судын юридик зат буларак бетерү чараларын уздыру**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судын юридик зат буларак бетерү чараларын уздыруны тәэмин итә.

6 статья. **Әлеге Законны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү**

Әлеге Законны гамәлгә ашыруга бәйле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

7 статья. **«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәреш кертү хакында**

«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясындагы беренче өлешенә (2004 елның 28 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 6; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция судында,» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

8 статья. **«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» 1999 елның 14 июлендәге 2284 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт

Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (I өлеш); 2003, № 8; 2006, № 2 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3; 2016, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның беренче өлешендәге 3 пунктында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 10 статьяның беренче өлешендә «Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисенең,» сүзләрен төшереп калдырырга.

9 статья. **«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 3 (3); 2003, № 8; 2008, № 11 (III өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяның 3 өлешендә «, Татарстан Республикасы Конституция суды» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 23 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 26 статьяда «Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисенә,» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 27 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисенә,» сүзләрен төшереп калдырырга.

10 статья. **Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 61 һәм $97^{4}$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш),

№ 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 61 статьяның 4 пунктындагы унсигезенче абзацында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) $97^4$ статьяның $2^1$ пунктындагы алтынчы абзацында «Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе,» сүзләрен төшереп калдырырга.

11 статья. **«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законының 26 статьясына үзгәреш кертү хакында**

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш); 2008, № 1, № 12 (VI өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2014, № 4; 2015, № 7 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

12 статья. **«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 3 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

2) $9^1$ статьяның 2 өлешендә «Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларыннан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 14 статьяда:

а) 2 өлешнең беренче абзацында «(Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларыннан тыш)» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 6 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

13 статья. **«Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе турында» 2010 елның 30 мартындагы 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 7 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 3), «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

14 статья. **«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8; 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 13 статьяда:

а) 1 өлешнең икенче абзацында «Татарстан Республикасы Конституция судына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә «Татарстан Республикасы Конституция судына,» сүзләрен төшереп калдырырга.

15 статья. **«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында**

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 19 статьясындагы 4 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), «һәм Конституция» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

**16 статья. «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 5 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 3 өлешендә «, Татарстан Республикасы Конституция суды» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 12 статьяның 3 өлешендә «, Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен «һәм» сүзенә алмаштырырга;

3) 13 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы Конституция судына,» сүзләрен төшереп калдырырга.

**17 статья. Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану**

Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» 1992 елның 22 декабрендәге 1708-XII номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12);

2) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» 1992 елның 22 декабрендәге Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 1998 елның 30 октябрендәге 1840 номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 11);

3) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2001 елның 28 июнендәге 947 номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 7 – 8);

4) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2001 елның 28 июнендәге 948 номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 7 – 8);

5) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2003 елның 21 октябрендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 10);

6) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан

Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2006 елның 20 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 2 (I өлеш);

7) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2006 елның 15 июлендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш);

8) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затларга таләпләрне төгәлләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 5 июлендәге 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (I өлеш);

9) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2008 елның 20 мартындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 3);

10) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 3 декабрендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 12 (I өлеш);

11) «Татарстан Республикасы Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2010 елның 3 июлендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш);

12) «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 10 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш);

13) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 93-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 11 (I өлеш);

14) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 26 мартындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 3);

15) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 40 һәм 41 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 26 октябрендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш);

16) «Татарстан Республикасы Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары

эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 1 мартындагы 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 19 (I өлеш);

17) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 17 июлендәге 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 60 (I өлеш);

18) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 112 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 ноябрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 1 (I өлеш);

19) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 7 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 37 (I өлеш).

18 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон, әлеге статьяда үз көченә керүнең башка срогы билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 7 – 17 статьялары 2022 елның 31 декабреннән үз көченә керә.

3. Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары өч ай эчендә үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 21 октябрь
№ 72-ТРЗ